Фамилиягез ______________________________
Исемегез ________________________________
Әтиегезнең исеме________________________

Номерыгыз [ ]

**ТЫҢЛАП АҢЛАУ**

Югары дәрәҗә: С1

**40 минут**

**Биремнәр бланкы**

**Эшне башкару өчен күрсәтмә**

Биремнәр бланкының өске өлешенә фамилиягез, исемегез, әтиегезнең исемен һәм номерыгызны языгыз. Шул ук мәгълүматларны 3 нче номерлы җаваплар бланкының өске өлешенә язып куегыз.
Сез җавап вариантларыгызны биремнәр бланкында да билгели аласыз. Биремнәрне эшләп бетергәч, җавапларыгызны җаваплар бланкына күчереп язарга онытмагыз. Инструктор биремнәрне эшләп бетерергә 10 минут кала сигнал бирәчәк.
Һәр өлеш башында эшне башкару өчен күрсәтмә һәм үрнәк бирелгән. Сез барлык биремнәрне үтәргә тиеш. Биремнәрне эшләп бетергәч, биремнәр һәм җаваплар язылган бланкларны инструкторга бирегез. Сорауларыгыз булса, Сез аларны хәзер бирә аласыз. Биремнәрне эшләгәндә, сораулар бирү һәм сөйләшү тыела.

**Тест турында кыскача мәгълүмат**

Биремнәрне эшләү вакыты: 40 минут
Өлешләр саны: 4
Биремнәр саны: 30
Баллар: һәр бирем 1 балл белән бәяләнә.
Гомуми баллар саны: 30

# ТЫҢЛАП АҢЛАУ ТЕСТЫ

**1 нче өлеш**

**Сез өч кыска диалог тыңларсыз. Һәр диалогка 3 җавап варианты булган 2шәр сорау бирелә. 1-6 нчы сорауларга туры килгән А, Ә яки Б җавабын билгеләгез. Сез аудиоязманы ике тапкыр тыңларсыз.**

**1 Борынгы татар милли киеме нинди өлешләрдән торган?**

А) төрле төсләрдәге тукымалар, күн һәм мех, энҗе һәм сәйләннәр.

Ә) эчке һәм тышкы кием, өс киеме, аяк киеме һәм бизәнү әйберләре.

Б) ирләр киемнәре, хатын-кызлар киемнәре, балалар киемнәре.

**2 Татар милли киеменең яңа стиленә этник төркемнәр нинди мөнәсәбәт белдергән?**

А) мишәр татарлары яңа стильне үзләре уйлап тапканнар.

Ә) барлык татарлар да XIX гасырда яңа стильгә күчкәннәр.

Б) керәшен татарларының милли киеме үзгәрмәгән.

**3 Әңгәмәдә сүз нәрсә турында бара?**

А) кайсы һөнәрләрнең аеруча кирәкле булулары турында.

Ә) баланың һөнәр сайлавында әти-әниләрнең роле турында.

Б) яшьләргә, һөнәр сайлаганда, игътибар ителәсе мәсьәләләр турында.

**4 Дөрес һөнәр сайлау өчен, белгечнең киңәше нинди?**

А) әти-әниләр киңәшен тыңларга һәм абруйлы югары уку йортын сайларга кирәк.

Ә) күп мәгълүмат тупларга һәм сайлауны үзеңә хәл итәргә кирәк.

Б) берьюлы ике җирдә укырга һәм күп һөнәрләр сайларга кирәк.

**5 Бүгенге көндә экологик проблемаларның иң зурысы булып нәрсә тора?**

А) урманнарның күпләп юкка чыгуы

Ә) сулыкларның кибүе

Б) һаваның пычрануы

**6 Әңгәмәдә радиотыңлаучыларга нинди киңәш бирелә?**

А) күпләп чишмәләр казырга

Ә) әйләнә-тирә мохитне сакларга

Б) сугару җирләрен киметергә

**2 нче өлеш**

**Сез Зөлфиянең төрле илләр һәм шәһәрләр турында сөйләвен тыңларсыз. 7-14 нче биремнәргә туры килгән җавапны сайлагыз. Сез монологны ике тапкыр тыңларсыз.**

Зөлфия үзенең төрле-төрле (7) _____________ баруы турында сөйли.
Беренче тапкыр (8) ________________ баргач, ул үзенә һәр ел саен нинди дә булса бер илне барып күрергә вәгъдә бирә.
Зөлфия (9) ________________ бару турында уйламый да, әмма океан буенда урнашкан ул ил аны һәрвакыт кызыктырып тора.
Ул танышлары белән бергә Американың бик күп (10)_______________ карап чыгарга өлгерә.
Зөлфия (11) _____________ һәм (12) ___________ кызлары белән бер өйдә яши.
Аңа (13) _____________ һәм 14) ____________ белән танылган ил ошый.

**3 нче өлеш**

**Сез Джулия Искәндәрова белән әңгәмә тыңларсыз. Соңыннан 15-20 нче биремнәрне үтәгез, А-В җаваплары арасыннан туры килгәнен сайлагыз. Һәр сорауга бер генә дөрес җавап булуын истән чыгармагыз.**

**15 Хәзерге вакытта Роберт һәм Джулия Искәндәровлар ...**
А) күп бәйгеләрдә катнашалар.
Ә) чит илләргә сәяхәт итәләр.
Б) югары уку йортында укыйлар.
В) Санк-Петербург шәһәрендә яшиләр.

**16 Джулия ханым .... дип саный.**
А) гаилә кору укуга зыян итми
Ә) гаиләле кешеләргә уку һәм эшләү кыенрак
Б) гаиләдә төп эшләрне ир-ат башкарырга тиеш
В) яшь гаиләләргә дәүләт ярдәм күрсәтергә тиеш

**17 Гаилә әгъзалары фикеренчә, һәр кеше ... белем алырга тиеш.**
А) югары
Ә) берничә уку йортында
Б) махсус
В) даими

**18 Бәйгедә катнашу гаиләне ....**
А) таныткан.
Ә) ныгыткан.
Б) җимергән.
В) үзгәрткән.

**19 Гаиләдә ризык пешерү ... йөкләнгән.**

А) Робертка
Ә) Джулиягә
Б) икесенә дә
В) кем өлгерә, шуңа

**20 Конкурста жюри әгъзалары ... мөкиббән киткән.**
А) Джулиянең җырлавына
Ә) Джулия пешергән ананаслы тапалган тавыкка
Б) гаилә әзерләгән гөмбәле ашка
В) аларның мәхәббәт тарихы сурәтләнгән видеога

**4 нче өлеш**
**БЕРЕНЧЕ БИРЕМ**
**Сез биш кыска монолог тыңларсыз. Һәр сөйләүченең үзенең яраткан эшен сайлау сәбәбен А-Д хәрефләре арасыннан сайлагыз. Бер җавап артык.**

| | |
|---|---|
| А якын-тирәдәгеләргә булышырга теләү | I сөйләүче____________________ (21) |
| Ә сәләтле булу | II сөйләүче__________________ (22) |
| Б яшьләрне аңларга теләү | III сөйләүче_________________ (23) |
| В җирне ярату | IV сөйләүче__________________ (24) |
| Г акча эшләү | V сөйләүче___________________ (25) |
| Д табигатьне ярату | |

**ИКЕНЧЕ БИРЕМ**
**Сез биш кыска монолог тыңларсыз. Һәр сөйләүченең яраткан эше турындагы фикерләрен А-Д хәрефләре арасыннан сайлагыз. Бер җавап артык.**

| | |
|---|---|
| А күңелне тынычландыра | I сөйләүче__________________ (26) |
| Ә көч бирә | II сөйләүче_________________ (27) |
| Б бер дә гади түгел | III сөйләүче_________________ (28) |
| В һәрвакыт хәрәкәтләнергә мәҗбүр итә | IV сөйләүче_________________ (29) |
| Г шәфкатьле эшләрнең берсе | V сөйләүче__________________ (30) |
| Д үземә вакыт калмый | |

**Җавапларыгызны 1 нче номерлы җаваплар бланкына күчерү өчен, Сезгә 8 минут вакыт бирелә.**

Фамилиягез ______________________
Исемегез ________________________
Әтиегезнең исеме_________________

Номерыгыз [ ]

**УКУ**

**Югары дәрәҗә: C1**

**1 сәгать 30 минут**

**Биремнәр бланкы**

## Эшне башкару өчен күрсәтмә

Биремнәр бланкының өске өлешенә фамилиягез, исемегез, әтиегезнең исемен һәм номерыгызны языгыз. Шул ук мәгълүматларны җаваплар бланкының өске өлешенә язып куегыз.
Сез җавап вариантларыгызны биремнәр бланкында да билгели аласыз. Биремнәрне эшләп бетергәч, җавапларыгызны җаваплар бланкына күчереп язарга онытмагыз. Инструктор биремнәрне эшләп бетерергә 10 минут кала сигнал бирәчәк.
Һәр өлеш башында эшне башкару өчен күрсәтмә һәм үрнәк бирелгән. Сез барлык биремнәрне үтәргә тиеш.
Биремнәрне эшләп бетергәч, биремнәр һәм җаваплар язылган бланкларны инструкторга бирегез.
Сорауларыгыз булса, Сез аларны хәзер бирә аласыз. Биремнәрне эшләгәндә, сораулар бирү һәм сөйләшү тыела.

## Тест турында кыскача мәгълүмат

Биремнәрне эшләү вакыты: 1 сәгать 30 минут
Өлешләр саны: 8
Биремнәр саны: 58
Баллар: **1-24** һәм **47-58** нче биремнәрдә дөрес җавап – 1 балл, **25-46** нчы биремнәрдә максимум 2 балл белән бәяләнә.
Гомуми баллар саны: 77

## УКУ

**1 нче өлеш**

**Текстны укыгыз һәм 1-8 нче биремнәргә туры килгән сүзне үрнәктәгечә билгеләгез.**

**ҮРНӘК:**

**0** А) күчерелмәләр Ә) чыганаклар Б) астөшермәләр В) искәрмәләр

| | |
|---|---|
| 0 | Ә |

КОЛ ГАЛИ

(якынча 1183-1236)

Кол Галинең тормышы хакында ______(0) юк дәрәҗәсендә. Әмма аерым мәгълүматлар шагыйрьнең тәрҗемәи хәле турында ______(1) мөмкинлек бирә.

Шагыйрьнең туган җире дип Чулман (Кама) буе санала. Кайберәүләр аны Зәй тамагына, ______(2) исә Кашан (Кышан) каласына нисбәт итәләр. Кашан шәһәре хәзерге Саескан Тавы тирәсендә булган дип уйланыла.

Кол Галинең туган елы итеп ________(3) 1183 ел алына. Ә инде шагыйрьнең үлү вакыты XIII гасырның 30 нчы еллар азагына – 40 нчы еллар башына, ягъни монголлар һөҗүме чорына туры килә.

Кол Гали әүвәл Болгар _____(4) укый, аннан Харәземдә һәм мөселман дөньясының кайбер башка төбәкләрендә дә белемен күтәрә, галимнәр, әдипләр белән аралаша. Кол Галинең бары бер әсәре – «Кыйссаи Йосыф» поэмасы гына билгеле.

Шагыйрь аны Тәүрат һәм Корьәндә ____ (5) кыйссалардан алып иҗат итә. Борынгы әдәбиятыбызның кыйммәтле _______(6) берсе булган бу поэма гасырлар буена _______ (7) хәлендә укылып, сакланып килгән. Алты гасыр буена кулдан күчерелә-күчерелә буыннарга тапшырылган әсәрнең текстында кайбер ялгышлар күбәйгәч, шагыйрь Габдерәхим Утыз Имәни 1824 елны, поэманың күп кенә борынгырак кульязмаларын җыеп, чагыштырып, төзәтеп-дөресләп чыга. Әсәрнең 1839 елны чыккан беренче басмасы Утыз Имәни төзәткән шул _____(8) нәшер ителгән дип уйланыла. Нәшире – Рәхмәтулла Әмирхан.

Татарлар күпләп яшәгән төбәкләрдә әсәрнең ике йөздән артык кульязма нөсхәләре һәм күчермәләре табыла.

**1** А) колак салырга Ә) фараз кылырга Б) күз йөртергә
В) сүз башларга

**2** А) икенчесе Ә) икенчеләре Б) икенче В) икәү

**3** А) шартлы рәвештә Ә) фаҗигале рәвештә Б) шул рәвешле
В) шулай итеп

| 4 | А) җөмһүриятендә | Ә) ширкатендә | Б) иминиятендә | В) мәмләкәтендә |
|---|---|---|---|---|
| 5 | А) игълан ителгән | Ә) фараз ителгән | Б) бәян ителгән | В) шөкер ителгән |
| 6 | А) чималларының | Ә) ядкәрләренең | Б) әйберләренең | В) күренешләренең |
| 7 | А) кульязма | Ә) ельязма | Б) язма | В) шаһәдәтнамә |
| 8 | А) нәшрияттан | Ә) җисемнән | Б) шәкелдән | В) нөсхәдән |

**2 нче өлеш**

**«Кара Аккош» татар интернет-журналыннан алынган өчпочмак пешерү рецептын укыгыз һәм 9-16 нчы биремнәрдә текстның эчтәлегенә туры килгән БЕР сүзне табыгыз. Җаваплар бланкында сүзне БАШ ХӘРЕФЛӘР белән языгыз.**

**ҮРНӘК:**

| 0 | К | А | М | Ы | Р |
|---|---|---|---|---|---|

1 нче эш. Камыр әзерләү

Җамаякка җылымса сөт салып, ак май өстәгез, чүпрә кушып җибәрегез, шикәр комы, тоз салыгыз һәм он иләгез, барысын бергә кушып болгатыгыз да _______(0) баса башлагыз. Камыр әзер булгач, аңа дүрт аш _____ (9) көнбагыш мае өстәгез. Камырның өстен каплагыз да бер _______ (10) җылы урынга куегыз (кабарырга тиеш, якынча 2 тапкырга арта).

2 нче эш. Эчлек әзерләү

Камыр кабара торганда, суган, вак кисәкләргә шакмаклап ит һәм бәрәңге ________(11). Табага дүрт аш кашыгы көнбагыш мае, 50 миллилитр тавык шулпасы салыгыз, шунда эчлекне бергә кушыгыз, кирәгенчә тоз белән борыч сибегез һәм барысын бергә ________(12). Шуннан җамаякка бушатыгыз һәм суынырга куегыз.

3 нче эш

Камырыгызны он сипкән куна тактасына алып куегыз да, озынча «колбаса» рәвешендә тәгәрәтегез, аннан 70-75 грамм зурлыгында кечкенә кабартмалар кисегез һәм 15 минут _______(13) киткәннәрен көтегез.

4 нче эш

Кабартма кисәкләреннән диаметры 15-16 сантиметрлы җәймәләр тәгәрәтеп ясагыз. Җәймәләр уртасына 80-82 грамм авырлыгында алдан эшләнгән эчлекне салып чыгыгыз.

5 нче эш

Эчлек салган җәймәне өч ягыннан тотып, бергә китереп кушыгыз да _______(14) өчпочмак формасында бөкләп чыгыгыз, ______(15) кечкенә тишек калсын.

6 нчы эш

Табаны сыек май белән майлагыз да шуңа өчпочмакларны тезеп чыгыгыз. Ике йомырка сарысын болгатып, шуны өчпочмак өсләренә сөртеп чыгыгыз. Өчпочмаклы табаны 150 градуска кадәр кыздырылган духовкага куегыз һәм 30-35 минут тотыгыз.

7 нче эш

Табаны мичтән алыгыз һәм 5-10 минут суынганын ________(16). Өчпочмакларны тәлинкәләргә тезеп чыгыгыз. Тәмле булсын!

© Халисә Мансурова

**3 нче өлеш**

**Матбугат.ру сайтыннан алынган язманы укыгыз. Уң якта баш хәрефләр белән бирелгән сүзләрне 17-24 нче биремнәргә туры китереп үзгәртеп языгыз.**

**ҮРНӘК**

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **0** | **б** | **е** | **р** | **е** | **н** | **ч** | **е** |

“Без – кырык ______ **(0)** ел балалары” спектакленең премьерасы — **БЕР**

2 һәм 3 нче май көннәрендә Кәрим Тинчурин _______ **(17)** Татар дәүләт драма һәм комедия театры Мөхәммәт Мәһдиев әсәре буенча куелган “Без – кырык беренче ел балалары” спектакленең премьерасын күрсәтә. — **ИСЕМ**

Спектакльне сәхнәгә театрның баш режиссеры Россиянең атказанган артисты, Татарстанның атказанган сәнгать ______**(18)** Рәшит Заһидуллин куйган. Рәссамы – Роман Моров (Татарстанның атказанган мәдәният ______ **(19)**). — **ЭШ**, **ХЕЗМӘТ**

Бөек Ватан сугышы чорының авыр шартларында педагогия училищесында укучы яшүсмерләрнең ________ **(20)** тормышы сурәтләнгән “Без – кырык беренче ел балалары” повесте 1968 нче елда языла. 1969 нчы елда “Казан утлары” журналында басыла, аннан өч тапкыр җыентыкларда, ике тапкыр рус телендә (Казанда һәм Мәскәүдә) дөнья күрә. Әдипнең җыйнак һәм күп _______ **(21)**, җор, үткен тел белән язылган әлеге повесте укучылар һәм әдәби тәнкыйть тарафыннан татар прозасындагы бер яңалык итеп каршы алына. Һәм шушы әсәре белән (“Атадан бала яшь кала”, Казан, 1969) М. Мәһдиев СССР Язучылар берлегенә әгъза итеп кабул ителә. — **КӨН**, **БИЗӘК**

“Безнең балалык еллары дәһшәтле Ватан сугышына туры килде. Бу китапны язар ________ **(22)** мин үземнең бала чагымны, үсмер елларымны тагын бер кат күңелдән кичердем. Шулай булгач, безгә бүген ничә генә яшь булмасын, кешеләр безне бүген кайсы буынга гына кертеп сөйләмәсен, мин _________ **(23)** исеменнән бер дә ______ **(24)** әйтә алам: без – кырык беренче ел балалары”, – дип язган М. Мәһдиев үзенең әлеге әсәрендә.

**АЛ**

**ЯШЬ**

**ШИК**

Спектакльдә Лия Вилданова, Резедә Сәләхова, Артем Пискунов, Илфак Хафизов, Булат Зиннәтуллин, Тимур Баһаветдинов катнаша.

**4 нче өлеш**

**25-30 нчы биремнәрдә беренче җөмләнең эчтәлегенә туры китереп, БАШ ХӘРЕФЛӘР белән бирелгән сүзне үзгәртмичә, икенче җөмләне тулыландырып языгыз. Һәр җөмләдә икедән ким, биштән артык сүз кулланырга ярамый. Җаваплар бланкына бары тик шул сүзләрне генә языгыз.**

**ҮРНӘК**

**0** ***Караңгы төшкәч, урамда утлар яна башлый.***

**БЕЛӘН**

***Караңгы _________, урамда утлар яна башлый.***

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **0** | **т** | **ө** | **ш** | **ү** | **б** | **е** | **л** | **ә** | **н** |

**25** Наилә сөйләшенгән вакытка килмәде, шуңа күрә Мансурны бик авыр хәлдә калдырды.

**АРКАСЫНДА**

Наилә сөйләшенгән вакытка ________, Мансурны бик авыр хәлдә калдырды.

**26** Алиянең быел алай каты ютәлләгәне юк, чөнки былтыр ул шифаханәдә бик озак дәваланып кайтты.

**БИРЛЕ**

Алиянең былтыр шифаханәдә бик озак _______ , алай каты ютәлләгәне юк.

**27** Организмда матдәләр алмашуын яхшыртыр өчен, гөлҗимеш чәе эчәргә кирәк.

**НӘТИҖӘСЕНДӘ**

Гөлҗимеш чәен ______, организмда матдәләр алмашуы яхшырырга мөмкин.

**28** Чишмәләрне карап, тазартып тормасаң, аларның суы саегырга, гомумән дә, кибәргә мөмкин.

**ӨЧЕН**

Чишмәләрнең суы саекмасын һәм, гомумән, _______, аларны карап, тазартып торырга кирәк.

**29** Илгиз дәүләт оешмасында эшли башлады, шуннан соң тормышлары җайланып китте.

**СОҢ**

Аларның тормышлары Илгиз дәүләт оешмасында ________ җайланып китте.

**30** Яшьләрне тәрбияләүгә җитәрлек игътибар бирелмәсә, хезмәт җитештерүчәнлеге түбән була.

**ҖИРДӘ**

Яшьләрне тәрбияләүгә җитәрлек _________ хезмәт җитештерүчәнлеге түбән була.

**5 нче өлеш**

**М.Мәһдиевнең "Без – кырык беренче ел балалары" повестеннан өзекне укыгыз. 31-36 нчы биремнәрдәге сорауларга туры килгән җавапны билгеләгез.**

Йокы килә

Авылдан училищега кадәр нәкъ унике чакрым. Тулай торакка кичтән барып кунасы килми. Ял көнне анда салкын, шыксыз була. Болай, ичмасам, атна кыскара: биш кич кунсаң, атна тәмамлана. Ләкин дүшәмбе көн иртән торып дәрескә баруы – әҗәл. Кемдер: «Дүшәмбе – авыр көн», – дип әйткән, имеш. Ул кеше моны инде дүшәмбе көн иртән йокыдан торуны искә алып әйткәндер.

Тышта әле караңгы. Утлар алынмаган. Буран себереп тора. Менә Рәдифләр тәрәзәсе. Ут юк. Рәдиф, сигезенчене бетергәч, прицепщик булып эшли башлады да менә кышкы төндә рәхәтләнеп йоклый. Алар өендә йокы аеруча тәмле. Менә киң чиста идән. Анда тәгәрәшеп Рәдифнең энеләре йоклый. Аска толып, тун җәйгәннәр. Чәбәләнеп беткәннәр. Бер энесенең аягы икенче бер энесенең муенына салынган. Ә иң кечкенәсе, ике яшьтәгесе, мүкәләгән килеш капланып яткан. Аларда һәр төнне шулай. Их, нигә генә укып йөрергә, нигә прицепка гына утырылмаган соң?

Авыл артта калды. Алда кара-кучкыл урман. Анда буран юк, бүрекнең колакларын ычкындырасың. Тып-тын, җылы. Менә аланда печән кибәннәре. Ул кибәннең астында бик рәхәттер. Анда берәр җәнлекнең оясы бардыр. Алар әтисе, әнисе, балалары бергә җыелышып, җир җиләге исе килеп торган печәндә рәхәтләнеп йоклыйлардыр. Их, нигә безнең заманда могҗиза булмый икән? Булсын иде менә шулай: синең каршыңа бер кеше килеп чыга. Ул сине таный. Болай ди:

– Энекәш, бүген уку төштән соң бит...

Менә шуннан, нәкъ шушы турыдан печән кибәннәре янына кереп китәр идең дә астына ук кереп йоклар идең. Озак итеп, рәхәтләнеп йокларга иде. Ләкин теге кеше чыкмый... Кибәннәр инде артта калдылар.

Яктыра башлады. Урман да бетте. Кырда салкынча, себерә торган буран. Иртәнге сорылыкта урман кырындагы училище бинасы күренә. Бер катлы агач йорт, урман буена сыя алмыйча, кырдагы кар диңгезенә таба сузылып таралып ята.

Класста җылы. Морҗа исе, башка тия торган зәңгәр ис. Бөтен буыннар талып кала, тар парта арасында тик утыруы шундый рәхәт... Ләкин күзгә нәрсәдер өелә, нәрсәдер укытучы өстәле яныннан очып килә, туп-туры синең күзеңне каплый, баш аска төшеп китә... Юк, бу әйбер бинокль икән. Әнә шуның ике трубасы эченә йокы тутырылган. Тыгызлап. Шул бинокль кара тактадан ычкына да, салмак кына тирбәлеп, синең күзеңә килеп терәлә. Менә труба эчендәге төтен сыман әйбер чыгып, синең күзләреңне каплый. Баш кисәк кенә аска сыгылып китүгә, бинокль юк була.

Әллә каян укытучы тавышы ишетелә:

– Баш килеш: Буран, Иялек килеше: Буранның, Юнәлеш килеше: Буранга, – дип нәрсәдер сөйли. Шул арада бу сүзләр барысы да вак кисәкләр булып оча башлыйлар. Аларның һәрберсе бер кисәк йокы икән. Алар күзгә килеп керәләр, башны авырайталар. Баш тула. «Буран, буранның, буранга... Буран, буранның, буранга...» Өстәл янында басып торган апа да һич тә укытучы түгел. Ул теге, печән кибәннәре янында очрарга тиешле кеше икән. Ул кеше дә түгел, әллә нинди мамык сыман төтеннән оешкан бер гәүдә икән. Ул үзе йокы икән. Менә ул аз-азлап йокы очырта икән.

– Буран, буранның, буранга... Буран, буранның, буранга...

Мамык сыман гәүдә бөтенләй таралып беткәч, барлык укучыларга, башларын өстәлгә салып, теләгәнчә йокларга рөхсәт ителәчәк икән... Юк, алай түгел, монда парталар юк, бу – печән кибәне төбендә икән. Менә хуш исле печәнне тишеп кергәннәр дә, йомшак тәпиләренә башларын салып, ике куян йоклап ята. Ул куяннарның берсе – баш килеш, икенчесе иялек килеше икән. Ә кибәннең бу ягын өстән зур итеп казыганнар. Анда Рәдиф үзенең энеләре белән йоклап ята. Кечкенә энесенең аяк бармагы Рәдифнең авызына ук тиеп тора, барысы да күкрәкләрен селкетә-селкетә мышныйлар. Шунда ук кибән төбендә бер патефон әйләнеп утыра. Пластинкадан бию такмагы ишетелә:

– Буран, буранның, буранга...

Шул көйгә кибән арасында бер олы апа бии. Үзе бии, үзенең күзләре йомык, рәхәтләнеп йоклый. Әһә, ул таныш кеше татар теле укытучысы Рабига апа икән. Куяннар да, Рәдиф тә, аның энеләре дә, Рабига апа да рәхәт чигәләр... Тик сине генә ниндидер ачы тавыш бүлдерә. Ул кыңгырау тавышы икән.

Грамматика дәресе тәмам.

Өйгә эш: «Чиләк» сүзен һәр ике санда төрләндереп дәфтәргә язып килергә...

Рабига апа җәнлек тиресеннән теккән соры тунының җиңеннән кулларын чыгара. Аның дәресе дүшәмбедә беренче сәгать булганлыктан, соңга калучылар да, йоклап утыручылар да була. Йоклаган укучыларга ул ачуланмый. Тик дәресеңне генә белеп кил.

– Сезнең каныгыз азайган, – ди ул. – Менә сугыш бетәр, теләгәнчә шикәр, яшелчә, җиләк-җимеш ашарсыз. Йоклау – кан азлыктан ул...

Шулай да йокы – рәхәт эш.

*М.Мәһдиев*

**31** **Автор бу текст аша ни әйтергә тели?**

А) Тилмереп укып йөрмәскә куша.

Ә) Дүшәмбе дәрескә йөрмәскә кирәк.

Б) Сугыштан соңгы авыл балаларының нинди шартларда һәм нинди хәләттә белем алып йөрүләрен сурәтли.

В) Азапланып укып йөргәнче эшләсәң, рәхәтләнеп йокың туйганчы йоклый алу турында әйтә.

**32** **Автор фикеренчә, Рәдифләрдә ни өчен йокы тәмле?**

А) Чөнки Рәдиф эшли, аның кебек укымый.

Ә) Идәндә йоклаганга.

Б) Толып өстендә йоклаганга йомшак, шуңа рәхәт.

В) Балалар күп булуга карамастан, рәхәтләнеп, әүмәкләшеп, бергәләшеп йоклаганга.

**33** **Әсәрнең герое нәрсә турында хыяллана?**

А) Иртә белән йокы туйганчы рәхәтләнеп йоклау турында.

Ә) Рәдиф кебек прицепта эшләү турында.

Б) Печән кибәннәре астына кереп, куяннар белән җылынып йоклау турында.

В) Рабига апаның дәресе тизрәк бетүе турында.

**34** **Герой фикеренчә, иң газаплы эш –**

А) Рабига апа дәресендә утыру.

Ә) Килешләрне өйрәнү.

Б) Атнаның беренче көнендә иртүк торып укырга килү.

В) Сүзләрнең йокы булып килеп кереп, башны авырайтуы.

**35** **Автор фикеренчә, геройның ни өчен йоклыйсы килә**?

А) Көн саен бик иртә торганга.

Ә) Сугыш вакытында тиешенчә туклану һәм тәрбия җитмәгәнлектән.

Б) Дәрес вакытында йокы тәмле булганга.

В) Рабига апаның тавышы ягымлы булганга.

**36** **Әсәрнең герое грамматика дәресендә үзен ничек тота?**

А) Йоклап китә.

Ә) Игътибар белән тыңлап утыра.

Б) Дәресне йокылы-уяулы үткәрә.

В) Печән кибәннәре, куяннар турында гына хыялланып чыга.

**6 нчы өлеш**

**Википедия сайтыннан алынган, татар халкының күренекле драматургы Т.Миңнуллин турында язылган текстны укыгыз. 37-40 нчы биремнәргә туры килгән дүрт бүлекнең (А-В) берсен билгеләгез.**

**А.** Туфан Габдулла улы Миңнуллин 1935 нче елның 25 нче августында Татарстанның Кама Тамагы районы Олы Мәрәтхуҗа авылында игенче гаиләсендә дөньяга килә. Әтисе Габдулла чыгышы белән – Казан кешесе, заманында Гафур Коләхмәтовтан белем алган. Алар укыган мәктәпкә Тукайның килүе, яхшы укучыларга китаплар өләшүе кебек истәлекләрен улына кат-кат сөйли.

Габдулла агай, гомумән, кызыклы шәхес була, аның тормыш юлы да катлаулы һәм кызыклы: дары заводы эшчесе Габдулла Миңнуллин 20 нче елларда авылга китә, авыл Советы секретаре булып эшли. Ул анда беренче мәртәбә радио керткән, велосипед алып кайткан. Беркадәр вакыт күмәк хуҗалык рәисе булып эшләгән. Габдулла агай үгет-нәсыйхәтле шигырьләр язган, экиятләр чыгарган. Малаена шул елларда дөнья шаулаткан шагыйрь исемен кушуы да аның әдәбиятка гашыйк булуын күрсәтә.

**Ә.** Башлангыч белемне авылларында алгач, Туфан күрше Олы Салтык авылында – җидееллык, Олы Карамалыда (язучы Ибраһим Гази авылы) унъеллык мәктәптә укый. Стена газеталары чыгаруда бик теләп катнаша, аларда өйрәнчек шигырьләрен бастыра. 1952 нче елда урта мәктәпне тәмамлый.

Белемгә омтылыш һәм әдәбиятка мәхәббәт Т. Миңнуллинны Казан университетына алып килә. Әмма сугыштан соңгы авыр еллар, гаиләгә ярдәм итү кирәклеге яшь егетнең тормыш юлына үзгәрешләр кертә: ул туган авылына кайта, төрле эшләрдә эшли. Олы Кариле һәм Кама Тамагы авылларында төрле урыннарда хисапчы хезмәтен башкара. Казанда хисапчыларны әзерләү курсларында укый, соңыннан комсомол юлламасы белән Казакъстанның Кустанай өлкәсендәге бер совхоз кооперациясендә баш хисапчы булып эшли.

1956 нчы елда университетка кабат килә, ләкин укый башлагач, Мәскәүгә, театр училищесына укырга китеп бара. Шулай итеп, 1956-1961 нче елларда Туфан Миңнуллин Мәскәүдә М.С.Щепкин исемендәге театр училищесында укый. 1961 нче елгы чыгарылыш яшьләре (бүгенге танылган

сәхнә осталары Ринат Тажетдинов, Равил Шәрәфиев, Әзһәр Шакиров, Нәҗибә Ихсанова, Наил Дунаев, Гөлсем Исәнгулова һ.б.) белән бергә, Т. Миңнуллин да Казанга кайта.

Шулай итеп, беренче карашка, Т. Миңнуллин – әдәбият һәм театр мохите тәрбияләп үстергән талант. Театр училищесында уку һәм Г. Камал театрында эшләү еллары, аннары телевидение һәм «Чаян»да эшләү чоры аны әдәбиятның авыр төрләреннән булган драматургияне үзләштерү өчен әзерлиләр. Ул сәхнә сәнгате серләренә төшенә, аның үзенчәлекләрен, тамашачы белән бәйләнеш булдыру өчен нәрсәләр кирәген белергә өйрәнә. Әмма бу талантның ачылып китүендә, мул җимешләр бирә башлавында тормыш, аны яхшы өйрәнү, кешеләрне белү, аңлый алу – төп сәбәпчеләрдән берсе. Т. Миңнуллинның беренче пьесаларына ук заманны һәм кешеләрне аңлау, көн сорауларына, заман агышына сизгерлек хас. Боларын исә иҗат кешесендә тормыш үзе булдыра һәм үстерә.

**Б.** Туфан Миңнуллин әдәбиятка 1960 нчы еллар башында юмористик хикәяләр һәм кечкенә күләмле сәхнә әсәрләре белән килә. Аның әдәби иҗат белән шөгыльләнә башлавы Мәскәүдә укыган елларына туры килә.

Бераздан зурлар өчен чорның актуаль мәсьәләләрен күтәргән, аны драматург итеп таныткан күләмле драмалар иҗат итә башлый. 1962 нче елны Туфанның «Безнең авыл кешеләре» исемле өч пәрдәле комедиясе – Минзәлә драма театрында, балалар өчен язылган «Азат» исемле пьеса-әкияте Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә куела һәм тамашачыларның игътибарын җәлеп итә. 1967-1969 нчы елларда Татарстанның Әлмәт дәүләт театрында – «Күрше кызы», Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында – «Миләүшәнең туган көне», ә Татарстан республика Күчмә театры (хәзерге К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры) сәхнәсендә «Нигез ташлары» һәм «Йөрәк янар өчен бирелгән» исемле яңа пьесалары куела. Шул вакытларда Туфан Миңнуллин әдәби тәнкыйтьтә өлгергән драматург буларак телгә алына башлый.

**В.** 70 нче елларда Туфан Миңнуллинның рәссам-драматург буларак иҗади йөзе формалаша, табигый таланты үзенчәлекле рәвештә ачылып китә һәм шәхси сыйфатларга байый бара. Драматург форма һәм эчтәлек өлкәсендәге эзләнүләрен тагын да тирәнәйтә төшә, тормыш материалын, үзен кызыксындырган, борчыган иҗтимагый һәм әхлак проблемаларын сәнгатьчә хәл итү, заман кешесенең рухи дөньясын, яшәеш фәлсәфәсен укучыга, тамашачыга үтемлерәк, тулырак итеп җиткерү өчен, сәхнә әдәбиятының төрле жанрларына һәм алымнарына мөрәҗәгать итә, иҗтимагый тормышның төрле-төрле темаларын кузгата.

Туфан Миңнуллин пьесаларының уңышы аларда сурәтләнгән вакыйгаларның тормышчанлыгы, реалистик нигезе белән аңлатыла. Язучы тормышны, аның үзгәрүле агышын нечкә сиземли, анда әледән-әле туып

торган әхлакый һәм мөһим социаль мәсьәләләрне оста тотып алып, аларны конкрет материал җирлегендә заманча яңгырашлы, сәнгатьчә тәэсирле-гыйбрәтле итеп сурәтли белә. Автор күпчелек әсәрләрендә олы фәлсәфи категорияләр турында – кешенең дөньяда яшәү мәгънәсе, аның җәмгыять һәм үз алдындагы гражданлык җаваплылыгы, әхлакый сафлыгы, намуслылыгы, туган җиргә, Ватанга тугрылыгы, үз халкының үткәненә ихтирамы һәм киләчәгенә ышанычы турында сүз алып бара.

Туфан Миңнуллин – пьесалары илебез сәхнәләрендә иң күп уйнала торган татар драматургларының берсе. Аның сәхнә әсәрләре Башкортстан театрларында («Диләфрүзгә дүрт кияү», «Үзебез сайлаган язмыш», «Ай булмаса, йолдыз бар», «Кырларым-тугайларым» һ. б.), Үзбәкстанның Мөкыйми исемендәге дәүләт музыкаль театрында («Диләфрүзгә дүрт кияү») һәм Хәмзә исемендәге Үзбәк дәүләт академия театрында («Әлдермештән Әлмәндәр») зур уңыш белән барды. «Әлдермештән Әлмәндәр» моңсу комедиясе шулай ук Шкетан исемендәге Мари дәүләт, Басарганов исемендәге Калмык дәүләт драма, Мурманск, Новокузнецк, Әстерхан, Горький, Мичурин һ. б. шәһәрләрнең рус драма театрлары сәхнәләрендә куелды; «Ай булмаса, йолдыз бар» драматик хикәясе Дагыстанда С.Стальский исемендәге Лезгин һәм Ә.Капиев исемендәге Лак дәүләт драма театрларында сәхнәләштерелде.

https://tt.wikipedia.org/wiki/Туфан_Миңнуллин

**Кайсы бүлектә:**

| | | |
|---|---|---|
| Туфан Миңнуллинның башка бик күп шәһәрләрдә дә уйналынган сәхнә әсәрләре телгә алына? | **37** | |
| Туфан Миңнуллинның әдәбият белән кызыксына башлавы хакында языла? | **38** | |
| Туфан Миңнуллинның кайларда белем алуы турында мәгълүмат бирелә? | **39** | |
| Туфан Миңнуллинда әдәби зәвык тәрбияләүдә тәэсире зур булган кеше сурәтләнә? | **40** | |

**7 нче өлеш**

**Татар халкының милли бәйрәме Сабан туе турында укыгыз. Текстта алты абзац төшеп калган. Текст азагында тәкъдим ителгән А-Е абзацларын 41-46 нчы биремнәргә туры китереп сайлагыз. Бер абзац артык.**

Сабан туе – татарларның иң билгеле милли бәйрәме. Бу бәйрәмне язгы кыр эшләре беткәч, май һәм июнь айларының соңгы көннәре аралыгында үткәрәләр. Бәйрәмнең конкрет датасы юк, ул шул язгы кыр эшләренең кайчан бетүенә бәйле. Нәрсә соң ул Сабан туе һәм аның татарлар өчен нинди әһәмияте бар?

| | |
|---|---|
| 41 | |

Татарстанда, Башкортстанда Сабан туе дәүләт бәйрәме биеклегенә кадәр күтәрелгән. Бәйрәм башта авылларда, аннан район үзәкләрендә, аннан соң инде республика үзәкләре Казан белән Уфада зурлап бәйрәм ителә. Сабан туен шулай ук татарлар яшәгән башка өлкәләрдә дә, хәтта татар диаспорасы булган чит илләрдә дә үткәрәләр хәзер.

Татардагы сабан сүзенең берничә мәгънәсе бар: тимер сука, сабан (яз чәчелә торган) культуралары, язгы кыр эшләре. Җирне яз сөргәннәр, сөрү иң авыр һәм күп хезмәт сорый торган эш булган, шуңа да татарлар барлык язгы чәчү эшләрен сабан дип атаганнар. Туй – татарча мәҗлес, бәйрәмне аңлатканга, күп вакыт Сабан туен русчага, артык гадиләштереп, “Праздник плуга” дип тәрҗемә итәләр.

| | |
|---|---|
| 42 | |

Алда әйтелеп кителгәнчә, татарлар һәм башка төрки халыклар бу бәйрәмне язгы кыр эшләрен уңышлы башкарып чыгу белән бәйлиләр, яз азагында, җәй башларында үткәрәләр. Тик гел алай булмаган. Казандагы ЮНЕСКОның Дөнья мәдәнияте институты ректоры профессор Энгель Таһировның мәгълүматлары буенча, татар Сабан туена – өч мең ел, ул башта яз һәм табигатьнең җанлануы бәйрәме булган.

Бу бәйрәм җәйләүгә чыгуның беренче көннәрендә, бияләрне сава башлап, беренче кымыз койган вакытта үткәрелгән. Күп кенә белгечләрнең фикеренчә, бу бәйрәм Саба туе дип аталган борынгы вакытта. Саба – татарча бөрдек дигәнне аңлата. Элек кымыз һәм башка сыек эчемлекләрне йөртер өчен, күчмә халыклар, шул исәптән татарлар да, кәҗә, сарык тиресеннән бөрдек дигән савыт-саба әзерли торган булганнар. Атта ияргә тагып йөртергә мондый савыт бик уңайлы булган. Себер татарларының кайберләре Сабан туен бүгенге көнгә кадәр Саба-туй дип атыйлар да.

Сабан туеның прототибы булган бу бәйрәмнәр Җыен дип аталган борынгы төрки-татар халыкларында. Җыен вакытында кабиләләрнең юлбашчысы һәм аксакаллары дала халкының төрле хуҗалык һәм сәяси мәсьәләләрен караганнар, мәсәлән, көтүлекләрне бүлешкәннәр, төрле сыйлар, мәҗлесләр, күңел ачулар оештырганнар, һәм дә, иң мөһиме, спорт ярышлары, көч сынашулар үткәргәннәр.

| | |
|---|---|
| 43 | |

Таһиров борынгы гомумдала уеннарын грек Олимпия уеннарыннан борынгырак, аларның беренче үрнәге булган дип тә исәпли һәм дә бу ярышларның шул вакытта Көнчыгыш Европа күчмә халыкларыннан (киммериялеләр, аларга кадәрге кабиләләрдән) грекларга кергән булу версиясен дә инкарь итми.

Борынгы күчмә халыкларның бу спорт ярышлары турында дәлилләр аз түгел.

| | |
|---|---|
| 44 | |

Хәзерге татар Сабан туеның башта борынгы күчмә һәм ярымкүчмә халыкларның бәйрәме булуы турында андагы милли спорт ярышлары да сөйли. Алар арасында – билбаулар белән милли көрәш. Билбаулар белән көрәш хәзер киң таралыш алып бара, континент һәм дөнья чемпионатлары үткәрелә, бу спорт төрен Олимпия уеннары исемлегенә кертү буенча да эш алып барыла. Белгечләр бу спорт төре җайдаклар алышыннан барлыкка килгән дип исәплиләр, ә җайдаклар алышы вакытында анда катнашучылар каршы якны, аның билбавыннан эләктереп, иярдән бәреп төшерергә омтылганнар.

Борынгы вакытта ук татарларның тормыш-көнкүреше һәм яшәү рәвеше ат белән бәйле булган. Еш кына татарлар, йөрергә өйрәнгәнче үк, ияргә утырганнар, җайдаклар булганнар. Атлар татарларның элек “фирма тамгасы” булган, чөнки татар атлылары хәрби тактикада бик көчле булганнар.

| 45 | |
|---|---|

Сабан туенда ат чабышлары – иң затлы бәйгеләрнең берсе. Атлылар мишеньгә уктан ату, сөңге ыргыту, мишеньгә аркан ташлау, икенче атны арканлау, җирдәге акча янчыгын (яки башка бер предметны) иелеп алып китү, божра ташлау яки, киресенчә, аны сөңге очына элеп алып китү кебек бәйгеләрдә үз осталыкларын раслаганнар. Болар барысы да бар көченә йөгереп барган ат өстендә эшләнгән.

Сабан туенда халык яратып карый торган уеннар, тамашалар күп, катнашырга, үз көчләрен, җитезлекләрен, осталыкларын сынарга теләүчеләргә ярышлар, уеннар җитәрлек. Бу тамашалар кызыклы һәм Сабан туена килгән һәр кеше катнашырлык. Шулар арасында: кул көрәше (армрестлинг); гер күтәрү; капчык белән сугышу; чүлмәк вату; авыш баганага менү; аркан, таяк тартыш; баганага үрмәләү; сулы чиләкләр белән, авызга йомыркалы кашык кабып, капчык киеп, аякларны кушып бәйләп, парлап йөгерү; катыктан тәңкә эзләү; тере балыкны кул белән тоту; тавык тоту; агач кисү һ.б. бар.

| 46 | |
|---|---|

Сабан туе милли җыр-биюләрне башкаручы үзешчән сәнгать коллективлары, билгеле артистлар башкаруындагы концертлар, татар милли йолалары, гореф-гадәтләре, тормыш-көнкүреш әйберләре, кәсепләре, милли ашлар белән таныштырулар аша бәйләнеп бара. Еш кына Сабан туенда Россиянең билгеле сәяси эшлеклеләре дә катнаша.

Хәзерге көндә татар бәйрәме Сабан туе милли кысаларда гына туктап калмый, киң, бөтен халык бәйрәменә әверелеп бара, дәүләт тарафыннан финанслана. Аны хәзер хезмәт һәм шатлык бәйрәме дип кенә түгел, ә халыклар дуслыгы бәйрәме дип тә атыйлар, чөнки бу бәйрәмдә күпмилләтле Россиянең бар милләт вәкилләре дә бик теләп катнаша. *Әлфир Гафуров.*

**А.** Борынгы җыен-сабантуйлары локаль характерда гына булмаганнар, ә бар Дала территориясендә дә үткәрелгәннәр. Тын океаннан (Кытай, Урта Азия) Каспий, Азов, Кара диңгезләр, Карпат тауларына кадәр сузылган Бөек Дала халкы үзенең иң көчле батырларын, иң оста мәргәннәрен, иң йөгерек чапкыннарын ачыклаган бу ярышларда. Борынгы Сабан туе вакытында, кагыйдә буларак, бер айга бар сугышлар, үзара ызгыш-талашлар туктатылып торган.

**Ә.** Сабантуй – чынлап торып массакүләм күңел ачу һәм спорт чарасы, бу чарада спортчылар гына түгел, ә бәйрәмгә килгән һәр тамаша кылучы катнаша ала. Соңгысы исә төрле кызыклы һәм көлкеле хәлләр, гомуми берләшкәнлек атмосферасы тудыра, шуңадыр да бәлки, Сабан туе – татарларның, гәрчә бер татарларның гына да түгел, ә башка халыкларның да иң яраткан бәйрәме.

**Б.** Хәзерге вакытта Сабан туена дәүләт бәйрәме дәрәҗәсе бирелде. Аңа хәзерләнү һәм бәйрәм итү буенча указлар, карарлар чыгарыла, бәйрәмне финанслау чыганаклары билгеләнә. Борынгы Сабан туе бәйрәме акрынлап матур, заманча традицияләр белән тулыландырыла. Шулай да бәйрәмебезнең асылы гасырдан-гасырга күчеп, сакланып килә.

**В.** Әгәр дә ат чабышлары, милли көрәш, баганага үрмәләү кебек ярышлар махсус физик әзерлек таләп итсә, калган ярыш һәм уеннарда, мәсәлән, капчык белән сугышуда, теләсә кайсы тамашачы катнаша ала. Менә шул вакытта сабан туеның кызыклы һәм көлкеле ягы күренә дә.

**Г.** Татарстан Тарих Институты директоры Р. Хәкимовның мәгълүматы буенча, башка халыклардагы, шул исәптән Европа халыкларындагы һәм Кытайдагы бар ат белгечлекләре заманында татарлардан алынган. Шуңа да ул халыклардагы атлы гаскәрләр “татар гаскәрләре” дип аталганнар да.

**Д.** Мәсәлән, Россия археологлары билбаулар белән көрәшүчеләр сурәтләре төшерелгән төрле савыт-сабалар, каеш аеллары, башка нәрсәләр табалар. Бу турыда Кытай чыганакларында да бар. Алтайдагы петроглифлар дип аталучы борынгы кыя рәсемнәрендә төрле җанварлар, аларны аулау күренешләре белән бергә, атта чабышлар, билбау көрәше күренешләре төшкән сурәтләр дә бар.

**Е.** Ә чынбарлыкта исә бу атама сүзнең өченче мәгънәсеннән – язгы кыр эшләре мәгънәсеннән алынган, Сабан туе – язгы кыр эшләрен уңышлы башкарып чыгу бәйрәме, булачак уңыш, бәрәкәт һәм муллык бәйрәме!

---

**8 нче өлеш**

**Камал театры сайтыннан (https://kamalteatr.ru/about-the-theatre/?lang=tat) кыскартылып алынган татар театры турындагы мәгълүматны укыгыз. 47-56 нчы биремнәргә туры килгән биш**

**абзацның (А-Г) берсен билгеләгез. Җавапларда абзацларны берничә тапкыр куллана аласыз.**

**А.** Халыкның талантын, рухи дөньясын, дәрәҗәсен билгели торган театр сәнгате – милләтебезнең казанышы һәм чиксез горурлыгы. Рус драматургы А.Н.Островский фикере белән әйткәндә, театр оешу – милләтнең камиллеген, өлгереп җиткәнлеген раслаучы зур тарихи вакыйга ул. Россиядә театр сәнгатенең XVIII гасыр урталарында мәйданга чыгуын искә алсак, империя биләмәләрендә туган милли театр өчен 100 ел аз тарих түгел.

Ил тарихы, халык язмышы белән бергә үрелеп барган театр биографиясендә XX гасырдагы иң әһәмиятле вакыйгалар урын алган – җиңүләр һәм фаҗигаләр дә, казанышлар, табышлар һәм югалтулар да җитәрлек анда. Бу иҗади эшчәнлектә дистәләгән, йөзләгән фидакарь, талантлы режиссер, драматург, артист, рәссам, музыкант һәм театр сәнгатен тудыручы башка һөнәр ияләре катнашкан.

**Ә.** XIX гасырның икенче яртысында татар дөньясында рус театры үрнәгендә милли драматургия һәм театр белән чын мәгънәсендә кызыксыну башлана, шуны кайгыртучы алдынгы фикерле әдәбият эшлеклеләре мәйданга килә. 1887 нче елда Габдрахман Ильяси тарафыннан “Бичара кыз” исемле беренче пьеса языла һәм өй шартларында куела. Бер елдан соң Фатих Халиди “Рәдде бичара кыз” драмасы белән бу өлкәдә икенче адым ясый. 1899 нчы елда булачак мәшһүр драматург Галиәсгар Камалның беренче әсәре булган “Бәхетсез егет” драмасы нәшер ителә, бер үк вакытта Гаяз Исхакыйның “Өч хатын белән тормыш” пьесасы да укучыларга барып ирешә. Мөгаллим, шәкерт, приказчик, гимназист яшьләр катнашында мәдрәсәләрдә, укымышлы гаиләләрдә өй шартларында спектакль-тамашалар уйнала башлый.

1905 нче елгы Беренче рус революциясе мәгърифәткә, мәдәнияткә, рухи ирекkә омтылган зыялыларыбыз өчен, димәк, гомумән татар халкы өчен дә зур этәргеч була. Милли матбугатка юл ачыла, татарча әдәби-музыкаль кичәләр ешая. Мәдәният үсешен чагылдырган мондый күренешләр халкыбыз яшәгән бик күп төбәкләрдә – Уфада, Оренбургта, Әстерхан, Орск, Уральск һ.б. шәһәрләрдә күзәтелә. Казандагы “Шәрекъ клубы”на (Татарстан урамы, 8 нче йорт) шимбә саен татарның укымышлы, зыялы яшьләре җыела. Шушы мәдәният учагына җыелган тамашачылар өчен тәүге һәвәскәр спектакльләрне оештыручылар да, катнашучылар да тарихта “шимбәчеләр” исеме белән танылган алдынгы яшьләрдән гыйбарәт. Татар театры туута, аның дөрес юнәлеш алуына Галиәсгар Камал, Габдулла Тукай, Гаяз Исхакый, Фатих Әмирхан, Гафур Коләхмәтов кебек талантлы яшь әдипләрнең тәэсире һәм ярдәме гаять зур була.

1906 нчы елның 22 нче декабрендә Казанда Яңа клубта (Горький урамы, 3 нче йорт) беренче тапкыр киң катлам тамашачылар өчен губернатор рөхсәте белән ярлы студентлар файдасына татарча ачык спектакль күрсәтелә, бу кичтә сәхнәдә “Кызганыч бала” драмасы һәм “Гыйшык бәласе” комедиясе уйнала. Казанны шаулаткан бу данлыклы вакыйга татар театрының туган көне булып тарихка керә.

**Б.** 1907 нче елның язында Оренбургта, әле 1905 нче елда ук уйналырга тиеш булып та, реакцион көчләр каршылыгы аркасында тыелган “Галимлек вә наданлык” (А.Островский буенча) һәм “Морад Сәлимов” (Ф.Халиди) спектакльләре уйнала. Казанда Татар укытучылар мәктәбен тәмамлаган күренекле шәхес, талантлы музыкант һәм җырчы Ильяс Кудашев-Ашказарский тарафыннан оештырылган, алдынгы фикерле татар егетләреннән торган әлеге төркем шул ук елны Идел буйлап беренче гастрольгә чыга.

Соңрак Түбән Новгородта труппага “беренче татар артисткасы” булып танылачак Сәхибҗамал Гыйззәтуллина-Волжская һәм үзе исән чагында ук “татар театрының атасы” дип йөртеләчәк, тарихка артист, режиссер, “Сәйяр” труппасының җитәкчесе Габдулла Кариев булып керәчәк 21 яшьлек Миңлебай Хәйруллин кабул ителә. “Сәйяр” – 1908 нче елда труппага Г.Тукай кушкан исем (күчеп йөрүче йолдыз мәгънәсендә). Татар театры үзенең беренче исеменә гасыр буе тугрылыклы калып ил гизә; ул халкыбыз яшәгән һәр төбәктә – Мәскәү, Санкт-Петербург, Баку, Уфа, Идел буе, Урал, Себер, Казахстан, Урта Азия шәһәрләре һәм Балтыйк буе республикаларында, ерак чит илләрдә гастрольләрдә булып, үзенең милли-мәдәни вазифасын зур фидакарьлек белән башкарып килә, милли театрны чын сәнгать югарылыгына күтәрә.

**В.** Гражданнар сугышы елларында артистлар төрле фронт бригадаларында кырыс, күчмә шартларда хезмәт күрсәтәләр. Урта Азиядәге тугандаш республикаларның милли театрларына беренче юл күрсәтүчеләр дә, бөтен ил буйлап дистәләгән татар театрлары тууга сәбәпче һәм аларга ярдәм итүчеләр дә татар артистлары була.

1922 нче елда асылда “Сәйяр” труппасы нигезендә һәм аңа төрле яклардан, төрле труппалардан артистлар, драматурглар, музыкантлар җыелу нәтиҗәсендә, дәүләт театры төзелә. Ул “Кызыл Октябрь исемендәге беренче татар дәүләт үрнәк драма театры” дип атала, аның җитәкчесе итеп Г.Кариевның шәкерте – артист, режиссер, драматург К.Тинчурин билгеләнә. 1926 нчы елда театр Академия исеменә лаек була, ә 1939 нчы елда Галиәсгар Камалның 60 еллык юбилее уңае белән театрга аның исеме бирелә.

**Г.** О.Пыжова, М.Чистяков һ.б. мәшһүр педагоглардан сәхнә серләренә өйрәнеп, 1950 нче елда Академия театрына яшь артистлар П.Исәнбәт, Р.Бикчәнтәев, Г.Камалова, Ш.Әсфәндиярова, Д.Ильясов, А.Хәйруллина һ.б.

килеп кушыла, бу талантлы төркем татар театрын яңа баскычларга күтәрә. Югары театр уку йортларында махсус белем алган тагын өч милли студия татар сәхнәсе тарихында лаеклы урын алып тора. Болар – Мәскәүнең М.Щепкин исемендәге Югары театр училищесында (1956–1961, 1984–1988), шулай ук Ленинград театр, музыка һәм кинематография институтында: (1968–1973 нче еллар) белем алган Р.Таҗетдинов, Р.Шәрәфиев, Н.Ихсанова, Ә.Шакиров, Н.Дунаев, Г.Исәнгулова, Ф.Әхтәмова, И.Әхмәтҗанов, Ш.Бариев, И.Төхвәтуллина, И.Габдрахманов һәм башкалар. Милли студияләрдә тәрбияләнгән бу артистларның иҗатыннан тыш театрның элеккеге һәм бүгенге репертуарын күз алдына да китереп булмый.

*Луара Шакирҗан*

---

**Кайсы абзацта:**

| | | |
|---|---|---|
| театр барлыкка килүдәге тәүге адымнар сурәтләнә? | **47** | |
| татар театрында югары үрләр яулаган, бүгенге көндә дә тамашачыларны сөендереп торган артистлар телгә алына? | **48** | |
| татар артистларының башка төбәкләрдә дә татар театры оештырылуына тәэсире ассызыклана? | **49** | |
| профессиональ татар театр труппасының яши башлавы хакында сүз бара? | **50** | |
| татар театры барлыкка килүгә зур өлеш керткән талантлы яшь язучылар мактала? | **51** | |
| беренче дәүләт театры төзелү турында әйтелә? | **52** | |
| театр сәнгатенең әһәмияте хакында сүз бара? | **53** | |
| Беренче рус революциясенең театр сәнгате үсешенә ясаган йогынтысы турында языла? | **54** | |
| данлыклы 60 нчы еллар буынына гомуми күзәтү ясала? | **55** | |
| данлыклы татар труппасы турында языла? | **56** | |
| иң беренче булып сәхнәләштерелгән драма әсәрләре хакында сүз бара | **57** | |
| театр труппасының Казаннан тыш башка җирләрдә дә чыгыш ясый башлаулары телгә алына | **58** | |

Фамилиягез ________________________
Исемегез ___________________________
Әтиегезнең исеме___________________
Номерыгыз

|  |
| --- |
|  |

## ЯЗУ

**Югары дәрәҗә: C1**

**1 сәгать 30 минут**

## Биремнәр бланкы

**Эшне башкару өчен күрсәтмә**

Биремнәр бланкының өске өлешенә фамилиягез, исемегез, әтиегезнең исемен һәм номерыгызны языгыз. Шул ук мәгълүматларны җаваплар бланкының өске өлешенә язып куегыз.

Биремнәрне башкарыр алдыннан һәр өлешкә караган күрсәтмәне игътибар белән укыгыз. Сезгә 1 нче өлештәге сорауга һәм 2 нче өлештәге СОРАУЛАРНЫҢ БЕРСЕНӘ җавап язарга кирәк була.

Биремнәрне җаваплар бланкында башкарырга кирәк. Ручка белән аңлаешлы итеп язу сорала, ихтыяҗ туганда, төзәтмәләр кертү рөхсәт ителә.

Биремнәрне башкаруга 1 сәгать 30 минут вакыт бирелә. Сез күрсәтелгән вакытка эшләрегезне тәмамларга тиеш.

Биремнәр һәм җаваплар язылган бланкларны инструкторга бирегез.

Һәр сорауга җавап бер төрле баллар белән бәяләнә.

**Тест турында кыскача мәгълүмат**

Биремнәрне эшләү вакыты: 1 сәгать 30 минут

Өлешләр саны: 2

Биремнәр саны: 4

Баллар: **1** нче бирем – 15 балл, **2-4** нче биремнәр 15 балл белән бәяләнә.

Гомуми баллар саны: **30**.

**1 нче өлеш**
**Биремдәге сорауга җавап бирегез. Тәкъдим ителгән стильдә махсус бланкларда 190-240 сүздән торган текст языгыз.**

**1** **Бүгенге көндә иң кирәкле 5 һөнәр турында эссе языгыз. Тәкъдим ителгән сүзләрне файдаланып, үз фикерегезне дәлилләгез.**

Дөньяда нинди генә һөнәрләр юк: бик авыр булып тоелганнары да, беренче карашка бик җиңел күренгәннәре дә, бары тик хатын-кызлар өчен дип саналганнары да, ир-атлар гына башкара ала дип уйланылганнары да һ.б. Кайсы гына һөнәр иясе булсаң да, үз эшеңә җаваплы карарга, бу өлкәдә белемле булырга кирәк.
1. җавапсызлык, салкын караш нинди нәтиҗәләргә китерә?
2. үз эшеңнең остасы булырга кирәк.
3. һөнәр сайлауда Сезнең киңәшләрегез.

**2 нче өлеш**
**2-4 нче сорауларның БЕРСЕНӘ җавап языгыз. Тәкъдим ителгән стильдә махсус бланкларда 190-240 сүздән торган текст языгыз. Сайлап алынган сорауның номерын җаваплар бланкының өске өлешендә шакмаклар эчендә күрсәтегез.**

**2** **Сез Интернет-журналда сәламәт яшәү рәвеше конкурсында катнашырга чакырган белдерү күрдегез, ди. Бу белдерү белән танышыгыз һәм үзегезнең тәкъдимнәрегезне язып җибәрегез.**

Мин бөтенләй авырый белмим. Аз гына температурам булса яки бераз тамагым шешсә, кәефем бик начар була, тыным кысыла. Нишләргә? Бөтенләй дә авырмас өчен, нинди чаралар күрергә? Ничек тукланырга? Ничек киенергә? Бу турыда Сездән тәкъдимнәр, киңәшләр көтеп калам!

**3** **“Мәгариф” журналы сайтында кызыклы бер конкурс турында игълан күрдегез, ди. Шунда катнашырга булдыгыз.**

**“Үлән чәенә күчәбез!”**
Хуш исле, ямьле май ае житте. Бакчаларда, болын-кырларда беренче чәчәкләр күренә башлады, үләннәр баш калкытты, кычытканнар күзгә күренеп үсте, димәк, беренче үләннәрне җыеп, кыш өчен киптерә

башларга да озак калмады. Дәвалау үзлегенә ия булган нинди үләннәр беләсез? Аларны ничек кулланырга?

**Иң эчтәлекле һәм дәлилле язмалар безнең сайтта басылачак, ә авторларын истәлекле бүләк көтә!**

**4** **Сез дустыгыздан электрон хат алдыгыз, ди. Дустыгызның сорауларына җавап биреп, аңа хат языгыз.**

Нурия, сәлам!
Синең белән күптән аралашкан юк. Хәлләрең ничек? Былтыргы кебек җиләккә йөрисезме? Без быел әнием белән җиләккә баргач, бер ташландык авылга килеп чыктык. Йортлар инде җимерелеп беткән, кайбер йорт урыннарында чокырлар гына калган. Әнием: "Бу – Орнаш дигән авыл," – диде. Кайчандыр монда тормыш гөрләп торган. 90 нчы елларда яшьләр шәһәргә күченеп китә башлаган, картлар үлеп беткән. Авылларыбызны ничек саклап калырга икән? Яшьләр авылдан китмәсен өчен, нинди шартлар тудырырга? Кешеләрне, җирне яратырлык, эштән курыкмаслык итеп, ничек тәрбияләргә? Сорауларым күп. Чишелешен табарга, зирәк дустым, бәлкем, син ярдәм итәрсең?..
Җавап көтеп калам.

Ихтирам белән дустың Кадрия.